КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 сентябрь г.Казань № 1080

2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм дәүләт хезмәте күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар;

2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга дәүләт хезмәте күләмнәре.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023/2024 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 22 сентябрь, 1032 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 5 сентябрь, 1080 нче карары белән расланды

2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше исеме (белгечлек) | Уку срогы, ай | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәрне һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүгә тракторчы-машинисты | 5 | 12 595 | 14 183 |

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 5 сентябрь, 1080 нче карары белән расланды

2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга дәүләт хезмәте күләмнәре

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше исеме (белгечлек) | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүчеләрне һөнәри әзерләүгә дәүләт хезмәте күләме, кеше |
|---|---|---|
| «Мамадыш политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |

_________________________